# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

**"Халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән яклау турында" Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2011 елның 28 апрелендә
кабул ителде

**1 статья**

"Халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән яклау турында" 2004 елның 8 декабрендәге 62-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, № 12 (II өлеш); 2006, № 7 (I өлеш); 2007, № 11; 2010, № 5 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2 статьяның беренче өлешендә "хокукый җайга салу" сүзләреннән соң "халыкара хокукның гомумтанылган принципларына һәм нормаларына нигезләнә һәм" сүзләрен өстәргә;

2) 4 статьяның беренче абзацында "гадәттән тыш хәлләрдән яклау" сүзләреннән соң ", шул исәптән су объектларында кешеләрнең иминлеген тәэмин итү," сүзләрен өстәргә;

3) 5 статьяда "гадәттән тыш хәлләрдән яклау" сүзләреннән соң ", шул исәптән су объектларында кешеләрнең иминлеген тәэмин итү," сүзләрен өстәргә;

4) 9 статьяның беренче өлешенә түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

"табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр килеп чыккан очракларда гражданнарга бер мәртәбә бирелә торган акчалата түләүләрне гамәлгә ашыру турында, бер мәртәбә бирелә торган акчалата түләүләрне гамәлгә ашыру очракларын билгеләүне, шулай ук күрсәтелгән түләүләр гамәлгә ашырылачак затлар даирәсен ачыклауны кертеп, карарлар кабул итү.";

5) 17 статьяда:

а) беренче өлештә "гадәттән тыш хәлләрдән яклау" сүзләреннән соң ", шул исәптән су объектларында кешеләрнең иминлеген тәэмин итү," сүзләрен өстәргә;

б) икенче өлештә "гадәттән тыш хәлләрдән яклау" сүзләреннән соң ", шул исәптән су объектларында кешеләрнең иминлеген тәэмин итү," сүзләрен өстәргә;

6) 18 статьяда "гадәттән тыш хәлләрдән яклауны" сүзләреннән соң ", шул исәптән су объектларында кешеләрнең иминлеген тәэмин итүне," сүзләрен өстәргә;

7) 19 статьяның беренче өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм алардан килгән зыянны бетерү буенча федераль законда билгеләнгән чараларны финанс белән тәэмин итү:

региональ һәм муниципальара характердагы (урман янгыннары аркасында урманнарда барлыкка килгән гадәттән тыш хәлләрдән тыш) – Татарстан Республикасының бурыч йөкләмәләре булып тора;

муниципаль берәмлек чикләрендә (территориясендә) (урман янгыннары аркасында урманнарда барлыкка килгән гадәттән тыш хәлләрдән тыш) – муниципаль берәмлекнең чыгым йөкләмәсе булып тора.".

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2011 елның 19 мае
№ 19-ТРЗ